**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2015 ел, 6 июль | № 493

г. Казань

«Казан төзелеш көллияте» һөнәри белем бирүче дәүләт автоном учреждениесен төзү турында

Татарстан Республикасында һөнәри белем бирү системасын реформалаштыру һәм һөнәри белем бирү оешмалары белән идарә итүгә эш бирүчеләрне җәлеп итү буенча чараларны тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. «Казан төзелеш көллияте» һөнәри белем бирүче дәүләт бюджет учреждениесенең һәм Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының гамәлдәге «Казан төзелеш көллияте» һөнәри белем бирүче дәүләт бюджет учреждениесенең төрен үзгәртү юлы белән, учреждение эшчәнлегенең төп максатларын саклап, «Казан төзелеш көллияте» һөнәри белем бирүче дәүләт автоном учреждениесен (алага таба – көллият) төзү турындагы тәкъдимнәрен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгын көллиятне гамәлгә куючы вазыйфаларын һәм вәкаләтләрен башкаручы Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы итеп билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына:

бер ай эчендә Көллият уставының яңа редакциясен расларга (алга таба – Устав);

Уставны теркәгән көннән соң, бер ай эчендә Көллиятнең күзәтү советы составын расларга;

ел саен, Уставы белән күздә тотылган төп эшчәнлек нигезендә, көллият өчен дәүләт хезмәтләрен күрсәтүгә (эшләрен башкаруга) дәүләт йөкләмәсен расларга.

4. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына бер ай эчендә көллияткә түбәндәгеләрне беркетергә:

даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукында – түбәндәге адреслар буенча урнашкан җир кишәрлекләрен:

Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Халезов ур., 26 йорт, гомуми мәйданы – 15 547 кв.метр, кадастр саны – 16:50:250266:3;

Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Халезов ур., 26 йорт, гомуми мәйданы – 19 294,07 кв.метр, кадастр саны – 16:50:250265:45;

Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Липатов ур., 26 йорт, гомуми мәйданы – 29 205 кв.метр, кадастр саны – 16:50:250265:46;

Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Горький исемендәге Крестьян хуҗалыклары ассоциация, гомуми мәйданы – 43 000 кв.метр, кадастр саны – 16:22:100404:14;

оператив идарә хокукында – түбәндәге адреслар буенча урнашкан, көллият эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте:

Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Халезов ур., 26 йорт, гомуми мәйданы – 8 197 кв.метр (уку-укыту корпусы бинасы);

Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Халезов ур., 26 йорт, гомуми мәйданы – 3 307,2 кв.метр (уку-укыту остаханәсе бинасы);

Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Халезов ур., 26 йорт, гомуми мәйданы – 1 772 кв.метр (уку-укыту остаханәсе бинасы);

Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Халезов ур., 26 йорт, гомуми мәйданы – 2 192,5 кв.метр (тулай торак бинасы);

Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Халезов ур., 26 йорт, гомуми мәйданы – 419 кв.метр (гараж);

Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Липатов ур., 25 йорт, гомуми мәйданы – 3 309,2 кв.метр (тулай торак бинасы);

Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Липатов ур., 25 йорт, гомуми мәйданы – 4 916,4 кв.метр (тулай торак бинасы);

Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Липатов ур., 25 йорт, гомуми мәйданы –3 138,4 кв.метр (уку-укыту-җитештерү корпусы бинасы);

Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Липатов ур., 25 йорт, гомуми мәйданы – 3 120 кв.метр (1 нче уку-укыту корпусы бинасы);

Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Липатов ур., 25 йорт, гомуми мәйданы – 208,5 кв.метр (гараж);

Татарстан Республикасы, Кама Тамагы район, Красновидово ав., гомуми мәйданы – 41,6 кв.метр (такта йорт, А лит.);

Татарстан Республикасы, Кама Тамагы район, Красновидово ав., гомуми мәйданы – 41,6 кв.метр (такта йорт, Б лит.);

Татарстан Республикасы, Кама Тамагы район, Красновидово ав., гомуми мәйданы – 41,6 кв.метр (такта йорт, В лит.);

Татарстан Республикасы, Кама Тамагы район, Красновидово ав., гомуми мәйданы – 41,6 кв.метр (такта йорт, Д лит.);

Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Халезова ур., 26 йорт, гомуми мәйданы – 1 342,8 кв.метр (склад бинасы);

Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Халезов ур., 26 йорт, гомуми мәйданы – 47,4 кв.метр (склад бинасы).

5. Дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанслар белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм аның үтәлешен финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2010 ел, 29 апрель, 308 нче карары

нигезендә, әлеге максатларга Татарстан Республикасы бюджеты турындагы законда тиешле финанс елына һәм план чорына күздә тотылган акча чикләрендә гамәлгә ашырыла, дип билгеләргә.

6. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәгенә, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә, Уставны раслаганнан соң бер ай эчендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елга урта звено белгечләрен әзерләү программаларын тормышка ашыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны һәм Татарстан Республикасының дәүләт һөнәр белеме бирү оешмалары мөлкәтен карап тотуга нормативлар чыгымнарны раслау турында» 2014 ел, 29 октябрь, 807 нче карарына әлеге карарның 1 нче пунктына туры китерү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында карар проектын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

7. Татарстан Республикасы Финанслар министрлыгына тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетының бюджет исемлегенә үзгәрешләр кертергә.

8. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\493.docx